**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 2 декабрендәге 4209 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 916 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Реклама турында»гы федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Казан шәһәрендә тышкы реклама өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 916 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 17 ноябрендәге 4009 номерлы, 2023 елның 20 апрелендәге 1143 номерлы, 2023 елның 17 июлендәге 1997 номерлы, 2023 елның 28 сентябрендәге 2864 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 3430 номерлы, 2024 елның 3 апрелендәге 1275 номерлы, 2024 елның 4 октябрендәге 4188 номерлы, 2025 елның 10 февралендәге 318 номерлы, 2025 елның 26 мартындагы 887 номерлы, 2025 елның 23 мартындагы 1602 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1. 2.2 пунктында:

1.1.1.1. өченче абзацны төшереп калдырырга;

1.1.1.2. дүртенче һәм бишенче абзацларда «кимендә 75,0 кв.м» сүзләрен «кимендә 150 кв.м» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 3.1 пунктының дүртенче абзацына түбәндәге җөмләне өстәргә: «Медиафасадларда һәм видеоэкраннарда тәүлекнең караңгы вакытында сурәтне динамик эффектлар кулланмыйча һәм ак фон кулланмыйча күрсәтергә, шулай ук сурәтләрне минутына бер тапкырдан да ешрак булмаган итеп, яктылыкны нуль күрсәткеченә кадәр акрынлап киметеп һәм аннан соң яктылыкны 10 секундтан

артык вакыт эчендә акрынлап арттырып алмаштыруны башкарырга тәкъдим ителә»;

1.1.3. 3.3.1 пунктчасының өченче абзацында «100,0 м кимрәк» сүзләрен «70,0 м кимрәк» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.4. 3.3.3 пунктчасында:

1.1.4.1. беренче абзацта «брандмауэрлар,» сүзен төшереп калдырырга;

1.1.4.2. җиденче абзацта «, ә брандмауэрлар урнаштырганда:» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.4.3. ундүртенче, унбишенче абзацларны түбәндәгечә бирергә:

«- әгәр реклама корылмасының аскы кыры торак йортлар түбәсеннән югарырак урнашкан булса, биеклеге ике катка кадәр булган, аны да кертеп, торак йортлардан кала, реклама корылмасының мәгълүмат кыры читеннән 120 градуслы почмак ясап урнашкан торак йортлар, белем бирү учреждениеләре, сәламәтлек саклау учреждениеләре, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең стационар учреждениеләре урнашкан объектлар тәрәзәләренә кадәр кимендә 70 м ераклыкта;

- Казан шәһәренең шәһәр мохите эстетикасына югары таләпләр куелган түбәндәге урамнары һәм гомумшәһәр юллары буйлап урнашкан биналарның, корылмаларның фасадларыннан кала, биналарның, корылмаларның фасадларында: Ямашев проспекты, Фатыйх Әмирхан урамы, Чистай урамы, Декабристлар урамы (Сибгат Хәким урамыннан алып Правосудие урамына кадәр), Ибраһимов проспекты, Академик Арбузов урамы, Җиңү проспекты, Себер Тракты урамы (Академик Арбузов урамыннан алып Мир урамына кадәр), Николай Ершов урамы (Чехов урамыннан алып Зинин урамына кадәр), Вишневский урамы, Марсель Сәлимҗанов урамы (Нурсолтан Назарбаев урамыннан алып Һади Такташ урамына кадәр)»;

1.1.4.4. сигезенче, тугызынчы, унынчы, уналтынчы, унҗиденче, унсигезенче абзацларны төшереп калдырырга;

1.2. 2 номерлы кушымтада II «Биналарда, корылмаларда урнаштырыла торган реклама корылмалары» бүлегенең 2.2 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**